Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

23 сентябрь, 2019 ел № 20

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 11 апрелендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Федераль мәгълүмат адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1999 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе нотариаты турында 1993 елның 11 февралендәге 4462-1 номерлы Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» (2016 елның 28 июлендәге 9 номерлы, 2019 елның 26 апрелендәге 10 номерлы карарларга үзгәрешләр белән) 2016 елның 11 апрелендәге 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымта № 1дә:

- исемендә һәм текстында «васыятьнамәләр таныклыгы буенча һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «ышаныч язуы буенча» сүзләрен исемдә һәм текстта «күчемсез милек белән идарә итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышанычнамә таныклыгы буенча» сүзләренә тиешле килешләрдә алмаштырырга;

- 1.4 пунктында 2 абзацны төшереп калдырырга;

- 2.10 пунктының 5 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.2. 6 нчы кушымтаның 1.5 пунктының 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.Н. Жуков